Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданка В.М. Омарова шикаятенә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2019 елның 5 июле

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү

тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка В.М. Омарова шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Л.В. Кузьмина мәгълүматын, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкилләре — Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының юридик бүлеге башлыгы Р.Г. Миңнеголов, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының юридик бүлеге әйдәүче киңәшчесе Ф.М. Мөхәммәдиева, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Л.П. Борисова, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенече буенча чакырылган — Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлеге башлыгы урынбасары А.Ә. Закирова мәгълүматын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эшләү бүлеге баш киңәшчесе Л.К. Вәлиуллина, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтле вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы М.Б. Сөнгатуллин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Э.С. Каминский, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге баш белгече Э.И. Гафиятуллина, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары М.Ш. Долгов, Татарстан Республикасында Кеше

хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары Р.И. Сәйфетдинова чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка В.М. Омарова «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 2.4 пунктындагы дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Конституция судына гариза бирүче мөрәҗәгать иткән вакытта гамәлдә булган шикаять белдерелә торган Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацында, 2016 елның 26 декабрендәге редакциясендә, ташлама-субсидия бирү, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен бурычлар булганда, җыелган бурычларны каплаганчы яки ташлама алучы аны каплау буенча килешү төзегәндә һәм (яки) үтәгәндә туктатылып тора, дип билгеләнгән.

«Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 11 мартындагы 168 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән дәгъва белдерелә торган норма яңа редакциядә бәян ителгән, аның буенча торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча бурыч

булган очракта, ташлама-субсидияләр бирү барлыкка килгән бурычларны түләп бетергәнгә һәм (яки) аны түләп бетерү буенча килешү төзегәнгә һәм (яки) алучы тарафыннан үтәлгәнгә кадәр туктатыла.

Шикаятьтән, аңа өстәмәләрдән һәм аларга кушып бирелгән документларның күчермәләреннән күренгәнчә, гражданка В.М. Омарова — 3 төркем инвалиды һәм 2014 елның февраленнән аңа Нигезләмә нигезендә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидия билгеләнгән. Каты көнкүреш калдыкларын чыгару хезмәте өчен бурычлар барлыкка килү сәбәпле, 2015 елның декабреннән аңа ташлама-субсидия бирү туктатып торылган. Шул ук вакытта, мөрәҗәгать итүче раславынча, коммуналь хезмәтләр өчен ул даими рәвештә түләү керткән һәм бу өлкәдә бурычлары юк. Ул билгеләгәнчә, үзенә ташлама-субсидия бирүне туктатып тору турындагы хәбәрнамәләрне ул алмаган, чөнки шикаять белдерелә торган норма түбәндәгеләрне билгеләми: ташлама-субсидияләр бирү кем тарафыннан һәм нинди формада туктатып торыла, ташлама-субсидияләрне туктатып тору турындагы мәгълүматны аларны алучыга җиткерү кирәклеге турындагы таләп, күрсәтелгән мәгълүматны ташлама-субсидия алучыга җиткерү механизмы һәм сроклары, ташлама-субсидия бирүне туктатып тору сәбәпләре һәм аны бирүне туктатып тору өчен нигез булган бурычлары булу вакыты.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук дәгъва белдерелә торган Нигезләмәдә «торак урын һәм коммуналь хезмәтләр» төшенчәсе бербөтен итеп тә һәм аерым-аерым да кулланыла дип күрсәтә. Аның фикеренчә, ташлама-субсидия бирүне бер үк вакытта торак урын өчен дә һәм коммуналь хезмәтләр өчен дә бурычлары булган очракта гына туктатып торырга мөмкин.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, гражданка В.М. Омарова «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм

икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 48 (икенче өлеш), 54 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең яки аларга өстенлекләр билгеләүнең теләсә кайсы рәвеше тыела; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, урындагы затлар, әгәр законда башкача каралмаган булса, һәркемгә аларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы үзләренең карарлары һәм башка материаллар белән танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш; һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән очракта һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгаручы яисә киметүче законнар чыгарылмаска тиеш.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану гамәлиятендәге мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән орган актының конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацы

әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора, чөнки шикаять белдерелә торган нигезләмә, ташлама-субсидияләр бирүне туктатып тору мөмкинлеген күздә тотып:

- нинди нигездә ташлама-субсидия бирүне туктатып тору мәсьәләсендә билгесезлек калдыра;

- күпме вакыт дәвамында бурыч булу ташлама-субсидия бирүне туктатып тору өчен нигез булмау срогын билгеләми;

- ташлама-субсидия бирү кем тарафыннан һәм нинди формада туктатылып торуны күздә тотмый;

- ташлама-субсидияләр бирүне туктатып тору турында мәгълүматны аларны алучыга җиткерү кирәклеге турында таләпләрне беркетми;

- күрсәтелгән мәгълүматны ташлама-субсидия алучыга җиткерү механизмын һәм срокларын билгеләми.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмә социаль яклау һәм торак законнары өлкәсенә кагыла. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» һәм «к» пунктлары) нигезендә социаль яклау, шулай ук торак законнары Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясында каралганча, Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының алар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла (2 өлеш); Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләр буенча, шулай ук Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча кабул ителгән федераль законнарга каршы килә алмый (5 өлеш). Күрсәтелгән конституциячел таләпләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларына да тулысынча кагыла.

Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау өлкәсендә максаты инвалидларга Россия Федерациясе Конституциясе белән каралган граждан,

икътисади, сәяси һәм башка хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруда башка гражданнар белән тигез мөмкинлекләрне шулай ук халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре нигезендә тәэмин итү булган дәүләт сәясәтен «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон билгели (алга таба шулай ук — 181-ФЗ номерлы Федераль закон). Күрсәтелгән Федераль законның 28.2 статьясындагы беренче һәм алтынчы өлешләре нигезендә Россия Федерациясе Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына, шул исәптән инвалидларга торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә социаль ярдәм чаралары күрсәтү буенча да, вәкаләтләрен тапшыра, ярдәм күрсәтү формасы Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

Тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашырып, шулай ук «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларын үз көчен югалткан дип тану турында» 2004 елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның аерым категорияләренә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары күрсәтү өлешендә «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты дәгъва белдерелә торган Нигезләмәне раслады.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенә федераль законнар нигезендә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, алар буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты социаль тәэминат өлкәсендә

бердәм дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша, Татарстан Республикасы территориясендә федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәү мәҗбүри булган карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара.

3. Татарстан Республикасы Конституциясенең 13 статьясы нигезендә аның 54 статьясы (беренче өлеш) белән үзара бәйләнештә Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм иркле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт, һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә. Мәгънәсе буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясе, шул исәптән аның 7, 39 (1 өлеш) статьялары белән билгеләнгән.

Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясе нигезендә, хокукый җайга салуны гамәлгә ашырганда, нинди генә өлкәдә булмасын, югары социаль яклауга мохтаҗ затлар буларак, инвалидларның мәнфәгатьләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алырга кирәк, бу инвалидларга төрле ярдәм чаралары күрсәтү максатыннан, конституциячел хокукларын гамәлгә ашырганда аларга өстәмә матди һәм башка мөмкинлекләрне гарантияләргә тиешле махсус хокукый механизмнар булдыруны күздә тота (2018 елның 13 мартындагы 593-О номерлы Билгеләмә).

3.1. 181-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 өлеше нигезендә инвалидларны социаль яклау — законнар һәм бүтән хокукый норматив актлар белән, пенсия тәэминатыннан тыш, билгеләнә торган, инвалидларга социаль гарантияләр тәэмин итә торган чаралар системасы. Әлеге Федераль законның 17 статьясындагы 13 өлеше һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 160 статьясындагы үзара бәйле нигезләмәләр нигезендә инвалидларга торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнарына 50 процент күләмендә ташлама бирелә. Әлеге социаль ярдәм чарасы компенсация характерында һәм инвалидларга Россия Федерациясе Торак кодексының 153 статьясындагы 1 өлеше нигезендә гражданнарның бурычы булган торак урын

һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга юнәлдерелгән. Шул ук вакытта Россия Федерациясе Торак кодексының 160 статьясындагы 3 өлеше нигезендә гражданнарга торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнарына компенсация торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлары булмаган очракта яисә гражданнар тарафыннан аны түләү буенча килешүләр төзегәндә һәм (яисә) аны үтәгәндә бирелә.

Россия Федерациясе Югары Суды күрсәткәнчә, Россия Федерациясе Торак кодексының 160 статьясы мәгънәсе буенча, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү — гражданнарның аерым категорияләренә федераль законнарда, Россия Федерациясе субъектлары законнарында һәм җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда аларның торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү белән бәйле чыгымнарын тиешле бюджет акчалары хисабына кайтару ул (Россия Федерациясе Югары Суды Пленумының 2017 елның 27 июнендәге 22 номерлы карарының 45 пункты).

Татарстан Республикасында карала торган компенсация бирү тәртибе һәм шартлары шикаять белдерелә торган Нигезләмә белән регламентланган, аның 1.1 пунктында торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидия (алга таба — ташлама-субсидия) рәвешендә бирелүе беркетелгән.

Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дәгъва белдерелә торган дүртенче абзацында торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурыч булган очракта, ташлама-субсидияләр бирү барлыкка килгән бурычларны түләп бетергәнгә һәм (яки) аны түләп бетерү буенча килешү төзегәнгә һәм (яки) алучы тарафыннан үтәлгәнгә кадәр туктатыла дип билгеләнә.

Китерелгән хокукый җайга салу үзенең хокукый мәгънәсе буенча Россия Федерациясе Торак кодексының 160 статьясындагы 3 өлешендә беркетелгән охшаш нигезләмәләргә туры килә, чөнки шикаять белдерелә торган нормада «бурыч булу» дигән сүзтезмәне үз эченә алган юридик конструкция асылда гражданның торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычларының фактта булуы ташлама-субсидия бирүне туктатып тору өчен

федераль законнарда билгеләнгән хокукый нигезне үзгәртми. Шул ук вакытта, Татарстан Республикасы Конституция суды билгеләгәнчә, мондый бурыч тулаем торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча да, шулай ук аталган һәр түләү төре буенча да барлыкка килергә мөмкин, чөнки Россия Федерациясе Торак кодексының 154 һәм 160 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләре буенча торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү структурасы аерым дифференциацияләнгән элементлардан тора, аларга, аерым алганда, торак урынны карап тоту өчен түләү һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү керә.

Шуның белән Нигезләмәнең дәгъва белдерелә торган 2.4 пунктындагы дүртенче абзацы, гамәлдәге хокукый җайга салу системасында үз урыныннан чыгып, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүнең теләсә кайсы состав өлеше буенча бурыч булу ташлама-субсидия бирүне туктатып тору өчен нигез булып тора дип билгели.

Шуның белән бергә Татарстан Республикасы Конституция суды торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә гражданнарга ташлама-субсидия бирү буенча мөнәсәбәтләрне җайга сала торган күрсәтелгән хокук нормаларыннан, шулай ук Россия Федерациясе Югары Суды Пленумының 2017 елның 27 июнендәге 22 номерлы карарының 47 пунктындагы аңлатмаларыннан чыгып, гражданинның торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлары булу үзеннән-үзе социаль ярдәм чаралары күрсәтүне туктатып тору яисә аларны күрсәтүдән баш тарту өчен һичшиксез нигез була алмый дип билгели, чөнки гражданинга торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидия бирү мәсьәләсе буенча вәкаләтле орган тарафыннан карар кабул ителгәнгә кадәр, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлар барлыкка килү сәбәпләрен билгеләү алдан булырга тиеш. Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурыч барлыкка килүнең нигезле сәбәпләре булганда, вәкаләтле орган гражданинга социаль ярдәм чаралары күрсәтүдән баш тарта алмый.

Моннан чыгып, Татарстан Республикасы Конституция суды хокук кулланучыга ташлама-субсидия бирүне туктатып тору турында карар кабул

иткәндә формаль якын килмәскә, дәгъва белдерелә торган норманы ирекле куллану мөмкинлегенә юл куймаска, киресенчә, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычларның булуы турында, аның барлыкка килү сәбәпләре турында вәкаләтле органга кергән мәгълүматны тикшерү максатларында, шул исәптән гражданинның мондый бурычы булу турындагы мәгълүмат эшләрнең гамәлдәге хәленә туры килү-килмәүне билгеләүдә дә тиешле гамәлләр кылырга кирәк дип саный.

3.2. Дәгъва белдерелә торган нормада бурычлар булу ташлама-субсидия бирүне туктатып тору өчен нигез булмаган конкрет срокны билгеләүче нигезләмәләр булмау мәсьәләсенә карата Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк дип саный.

Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацын күрсәтелгән өлештә Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә дип тануны таләп итеп, мөрәҗәгать итүче фактта билгеле бер вакыт эчендә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурыч ташлама-субсидия бирүне туктатып тору өчен нигез булып тормаган хокукый чара билгеләүне таләп итә. Шул ук вакытта дәгъва белдерелә торган җайга салу торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурыч барлыкка килгән очракта ташлама-субсидия алу мөмкинлеген тәэмин итә торган конкрет хокукый чараларны ныгыта. Мондый хокукый чаралар дип гражданинның килешү төзү хокукын санарга кирәк, анда барлыкка килгән бурычны түләү шартлары һәм тәртибе, шулай ук гражданинның бурычларын түләгәннән соң ташлама-субсидия алу хокукы билгеләнә, шул исәптән аны бирү туктатылып торган айлар өчен дә түләнә (Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы бишенче абзацы). Татарстан Республикасы Конституция суды, шулай ук әлеге Карарда ачыкланган дәгъва белдерелә торган норманың конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, күрсәтелгән хокукый чараларга вәкаләтле орган тарафыннан бурыч барлыкка килү сәбәпләренең, шул исәптән аның барлыкка килү чоры дәвамлылыгының нигезле булу-булмавын ачыклау зарурлыгы да керә дип саный.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып һәм гражданнарның ташлама-субсидия алу хокукын гамәлгә ашыру турыдан-туры торак урын һәм коммуналь

хезмәтләр өчен түләү буенча үз бурычларын намуслы үтәү белән бәйле булу фактын игътибарга алып, Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге хокукый чаралар вакытында түләү кертү мөмкин булмаган хәлдә калган гражданнар өчен җитәрлек дәрәҗәдә яклау функциясен үти, дигән нәтиҗәгә килә. Шуңа бәйле рәвештә, моңа өстәп, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә нинди дә булса срок билгеләү гамәлдәге җайга салу кысаларында объектив зарурлыкка ия түгел, ә мондый срокның булмавы үзеннән-үзе гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылу турында сөйли алмый.

3.3. Россия Федерациясе Конституция Суды тарафыннан берничә тапкыр чагылдырылган хокукый позициядән күренгәнчә, законның гамәлдә булу механизмы тиешле хокук мөнәсәбәтләре субъектларына, барыннан да элек, конкрет норматив нигезләмә эчтәлегеннән яисә норматив нигезләмәләрнең үзара бәйләнешендә булган системадан чыгып, аңлаешлы булырга тиеш; шул ук вакытта хокукый җайга салуның тиешле ачыклык дәрәҗәсе хокукый күрсәтмәләрнең тагын да катлаулырак үзара бәйләнешләрен ачыклау юлы белән ирешелергә мөмкин булган очраклар да искәрмә түгел (1997 елның 23 декабрендәге 21-П номерлы, 1999 елның 23 февралендәге 4-П номерлы, 2013 елның 22 апрелендәге 8-П номерлы, 2015 елның 25 июнендәге 16-П номерлы карарлар һ.б.).

Китерелгән хокукый позиция Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацының конституциячеллеген бәяләгәндә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ташлама-субсидияләр бирү кем тарафыннан һәм нинди формада туктатып торылуын ачыклый торган нормаларның булмавына кагылышлы һәм ташлама-субсидияләр алучыга аларны бирүне туктатып тору турында мәгълүматны, шул исәптән мондый мәгълүматны җиткерү механизмы һәм сроклары турында белешмәләрне җиткерү зарурлыгы турында таләпне регламентлаучы аспектларда тулы күләмдә кулланыла.

Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацында ташлама-субсидияләр бирүнең кем тарафыннан һәм нинди формада туктатып торылуына күрсәтмәләр булмауга карамастан, бу аның хокукый эчтәлегенең билгесезлеген күрсәтми,

чөнки аны куллану Нигезләмәнең башка нормалары белән дә (1.2, 2.2—2.7 пунктлары), шулай ук башка норматив хокукый актлар белән дә, аерым алганда, «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәген булдыру турында» 2005 елның 20 июнендәге 296 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән дә тыгыз бәйләнгән, алар нигезендә ташлама-субсидияләр бирү, туктату, ташлама-субсидияләр бирүне туктатып тору (яңарту) кебек үк, Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлекчәләре компетенциясендә тора һәм аның карарлары рәвешендә кабул ителә.

Дәгъва белдерелә торган нигезләмәдә ташлама-субсидияләр бирүне туктатып тору турында мәгълүматны алучыга җиткерү зарурлыгына таләп булмауга килгәндә, мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать иткән вакытта Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы белән расланган Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турындагы 1 номерлы кушымтада әлеге мәсьәлә хәл ителгән булган, анда гражданинның әлеге мәгълүматны алырга ризалыгы күрсәтелгән, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында (язмача, телефон буенча, смс-хәбәр белән, электрон почта аша, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша) тәкъдим ителгән гариза формасы китерелгән.

Административ регламентның эчтәлеген анализлау ташлама-субсидия бирүне туктатып тору процедурасы әлеге дәүләт хезмәтен күрсәтүнең бердәм механизмының бер элементы булып тора дип раслый. Бу ташлама-субсидия бирүне туктатып тору турында гражданнарга хәбәр итү ташлама-субсидия билгеләү (билгеләүдән баш тарту) өчен Административ регламентта билгеләнгән формаларда гамәлгә ашырылырга тиеш булган дигәнне аңлата.

Хәзерге вакытта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм

коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында” 2006 ел, 24 март, 126 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 11 мартындагы 168 номерлы карары белән 2.4 пункты алтынчы абзац белән тулыландырылды, аның нигезендә ташлама-субсидия бирүне туктату (яңадан башлау) турындагы карар алучыга гариза бирүче тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга смс-хәбәр итеп) кулланучыга җиткерелә.

Дәгъва белдерелә торган нигезләмәнең конституциячеллеген ташлама-субсидия бирүне туктатып тору турында аны алучыга мәгълүмат җиткерү сроклары булмау өлешендә дә шулай ук бәяләргә кирәк. Карала торган норманы күрсәтелгән аспектта бәяләү Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге (аның филиаллары) шул исәптән гражданнарга торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирүгә кагылышлы мәгълүмат кабул итү (тапшыру) буенча эшчәнлеген регламентлаштыручы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 22 гыйнварындагы 20 номерлы карары белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенең (алга таба — Тәртип) нигезләмәләренә мөрәҗәгать итмичә мөмкин түгел.

Шулай итеп, әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы 8 пунктчасы нигезендә, торак урыннар һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычларның булмавы турында мәгълүматларны исәпләү һәм тапшыру, бурычларны түләү буенча гражданнар тарафыннан килешүләр төзү һәм (яки) үтәү турында белешмәләр хисаптан соң килүче айның 3 числосына кадәр электрон формада бирелә. Тәртипнең 6 пунктындагы 20 пунктчасы нигезендә кредит учреждениеләре тарафыннан гражданнарның шәхси (кертем) счетларына алга

таба торак урын, коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр күчерү өчен һәм почта элемтәсе бүлекләре яки түләүләрне китереп бирү оешмалары тарафыннан акча күчерү түләү аеның 9 числосына кадәр башкарыла.

Китерелгән нигезләмәләрнең шикаять белдерелә торган норма белән логик-хокукый бәйләнешен, шулай ук алар тарафыннан җайга салына торган хокук мөнәсәбәтләре өлкәсенең бердәм табигатен исәпкә алып, әлеге сроклар ташлама-субсидия алучыга аны бирүне туктатып тору турында хәбәр иткәндә дә тигез дәрәҗәдә кулланыла дигәнне аңлата. Ягъни, хисаптан соң килүче айның 3 числосына кадәр вәкаләтле органга гражданин тарафыннан торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертү турында мәгълүматлар алынмаса һәм шуның нәтиҗәсендә бурыч барлыкка килсә, вәкаләтле орган түләү аеның 9 числосыннан да соңга калмыйча гражданинга ташлама-субсидия бирүне туктатып тору турында һәрхәлдә хәбәр итәргә тиеш.

Димәк, дәгъва белдерелә торган җайга салу нормасында ташлама-субсидия бирүне туктатып тору турындагы мәгълүматны алучыга җиткерү вакытын билгели торган җайга салуның булмавы үзеннән-үзе мондый хәбәр итү чоры иректә һәм чикләнмәгән вакыт эчендә мөмкин булуы турында белдерми.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацы җитәрлек дәрәҗәдә ачык итеп федераль һәм республика законнары нигезендә ташлама-субсидия бирүне туктатып тору тәртибен һәм шартларын күздә тота, шулай ук Нигезләмәнең үзара бәйле башка нормалары белән үзеннән-үзе кеше һәм гражданның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара, чикли яисә башкача боза торган итеп карала алмый һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 48 (икенче өлеш), 54 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына каршы килми.

4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану ташлама-субсидияләр бирүне туктатып тору тәртибен һәм шартларын камилләштерүгә комачауламый.

Татарстан Республикасы Конституция суды дәгъва белдерелә торган нигезләмәне куллану гражданнарга лаеклы тормышка бирелгән хокукның асылына, шул исәптән гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү чараларын алуга да кагылмаска тиеш, шулай ук закон өстенлеге, тигезлек һәм гаделлек, гражданнарның законга һәм дәүләт гамәлләренә ышанычын саклау принципларын бозуларга юл куймавына игътибар итәргә кирәк дип саный.

Шуңа бәйле рәвештә дәгъва белдерелә торган актта ташлама-субсидияләр бирүне туктатып тору тәртибен һәм шартларын тулырак һәм җентекләбрәк ныгыту, шул исәптән ташлама-субсидия алу хокукына ия булган гражданнарны кызыксындыру максатларында аларның бурычлары булуы турында гражданнарга мәгълүмат бирү срогын билгеләү, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча үз йөкләмәләрен намус белән үтәргә, карала торган хокукый җайга салуда ачыклык, билгелелек һәм мәгънә берлеге булуга ярдәм итәр иде. Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә (2001 елның 13 декабрендәге 16-П номерлы, 2004 елның 17 июнендәге 12-П номерлы һәм 2008 елның 27 ноябрендәге 11-П номерлы карарлар), шулай ук Кеше хокуклары буенча Европа Суды практикасына туры килә (2007 елның 24 маендагы «Игнатов (Ignatov) Россия Федерациясенә каршы» эше; 2007 елның 24 маендагы «Владимир Соловьев (Vladimir Solovyev) Россия Федерациясенә каршы» эше буенча карарлар).

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 статьяларына һәм 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазифаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы нигезендә әлеге Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

**№ 84-П**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**